КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 23 декабрь г.Казань № 1404

«Татарстан Республикасының энергия ресурслары нәтиҗәлелеге технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчән-леген арттыруга адреслы ярдәм» төбәк проектын гамәлгә ашыруга субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 781 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хезмәт җитештерүчәнлеге» милли проекты нәтиҗәләренә ирешүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 26 апрелендәге 510 номерлы, «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән «Татарстан Республикасының энергия ресурслары нәтиҗәлелеге технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесенә «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга адреслы ярдәм» төбәк проектын гамәлгә ашыруга субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен расларга.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Предприятиеләрдә хезмәт җитеште-рүчәнлеген күтәрүгә адреслы

ярдәм күрсәтү» федераль проекты кыса-ларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитеш-терүчәнлеген тотрыклы үстерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чара-ларны Татарстан Республикасында тормышка ашыру чаралары турында» 2019 ел, 07 сентябрь, 802 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген тотрыклы үстерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны Татарстан Республикасында тормышка ашыру чаралары турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 802 нче карары белән расланган «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектының «Предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә адреслы ярдәм күрсәтү» федераль проекты кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген тотрыклы үстерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансферт рәвешендә бирелә торган акчаны тоту тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 ел, 17 февраль, 115 нче карары.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин